РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» июнь 2025 ел г. Альметьевск № 1543

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе гражданы (чит ил гражданы) тарафыннан махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүдә ярдәм күрсәткән затларга өстәмә социаль ярдәм чарасы бирү тәртибен раслау хакында» 2025 елның 14 апрелендәге 802 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә, гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе гражданы (чит ил гражданы) тарафыннан махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүдә ярдәм күрсәткән затларга өстәмә социаль ярдәм чарасы бирү тәртибен раслау хакында» 2025 елның 14 апрелендәге 802 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. карарның 1 нче кушымтасының 3 пунктындагы икенче абзацында «2025 елның 1 июненә кадәр» сүзләрен «2025 елның 1 августына кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. карарга 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«14» апрель 2025 ел №802
карары белән расланган
3 нче кушымта

заказ № 1-851

Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүдә Россия Федерациясе гражданы (чит ил гражданы) тарафыннан ярдәм күрсәткән затларга өстәмә социаль ярдәм чарасы бирү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Каюмов А.М. | Комиссия рәисе, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары. |
| Фәсхетдинов И.Р. | Комиссия рәисе урынбасары, Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |
| Соколова Ю.В. | Комиссия секретаре, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек идарәсенең җәмәгать иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| | Комиссия әгъзалары: |
| Гафуров Р.Р. | Әлмәт муниципаль район Советының мобилизация бүлеге башлыгы (килешү буенча). |
| Корников Р.А. | Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре һәм Әлмәт муниципаль районы хәрби комиссары (килешү буенча).». |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 2 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М. Каюмовка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.М. Хәбутдинова